Элек-электән Мордовиянен татар авыллары клубларында vзәшчән коллективлар театр куеп килделәр. Аннары бу әш бик сирәк авылларда гына калды; әмма бу гадәт vлмәде - яши. Шулай, апрельнен 25ндә Ромоданово районы Алтар авылы мәдәният йортынын «Синен очен» драма тvгәрәгендә катнашучылар тарафыннан Рәмзия Хосәенованын «Табылдык» пьесасы буенча монсу комедия сәхнәләштерделәр.
«Синен очен» драма тvгәрәген Мәдәният йорты житәкчесе Альфия Хафиз кызы Илькаева алып бара. Алар репертуарында Галиәсгәр Камаловнын «Беренче театр», Голшат Зәйнәшеванын «Гайфи бабай, ойлән давай!» һәм башкалар бар. Район драмтvгәрәк конкурсларында призлы урыннар яулыйлар: быел 1 урын аларнын! Ярыш 5 елга бер тапкыр vтә.

Ә хәзер артистлар турында. 95 яшьлек Әсмабикә әбине Алтар китапханәчесе Сария Айса кызы Арсланова уйный. Анын 10 яшьлек оныгы Альбинаны 5 сыйныф укучысы Риана Яфарова башкара. Алтар пенсионеры Ряхилә Соләйм кызы Илкаева 90 яшьлек ялгыз яшәvче Хәерниса әби ролен, 80 яшьлек Гатия образын шулай ук Алтар авылы пенсионеры Алия Исхак кызы Халитова, ә 95 яшьлек ялгыз Сылубикә әбине тvгәрәк житәкчесе Наимә Хәйдәр кызы Кадеркаева уйныйлар. 35 яшьлек хат ташучы Разия ролен Алтар хужабикәсе Екатерина Николаевна Исмаилова, 45 яшьлек ойләнмәгән Маннурны бvгенге студент Ильдус Ильдар улы Абушаев, шәфкать туташын Алтар мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып хезмәт иткән Диана Наиль кызы Нугаева башкаралар. Биюче кызларлар, малайлар - Кузяева Аиша, Юнусова Гельназ, Исхакова Малика, Саттарова Амира, Нугаев Ильдар, Хамидуллов Хайрулла.
Алар барысы да артист исемен аклап, ярышта беренчелекне алдылар. Авыл халкы да бик жылы каршы ала vз артистларынын унышлы чыгышын. Алтар кешеләренен бер олеше бу сәхнә әсәрен кvреп олгермәгән, спектакльне тагы куюларын сорыйлар. Әйтеп китәргә кирәк, 28 апрельдә Ромодановода «Табылдык» пьесасынын озеген кvрсәткәннәр инде. Рәмзия Хосәенованын «Табылдык» пьесасы буенча монсу комедиянен сюжеты бvгенге елларда бара. Сугыштан сон ялгыз хатын-кызлар, ярым буш авыллар проблемасы тирән ачыла. Чаганлы авылынын дvрт йортында әбиләр яши. Аларнын очесенен ирләре Боек Ватан сугышыннан кайтмаганнар. Инде 70 елдан артык вакыт vткән. Бvгенге топ вакыйгалар турында хат ташучылары Разыя аша гына беләләр. Разыя шул берничә бертек әбиләренә азык-толек тә китерә.
Белгәнебезчә, жәй коннәре авыллар жанлана. Сәхнәләштерелгән әсәрдә дә һәр жәй Әсма әбисенә, кунакка ераста яшәvче дингезче улынын кызы Альбина оныгы, жәйге ялга килә. Альбинага авылда бик ошый. Балачактан ул әбисендә тәрбияләнә, ә улы, vз чиратында, әнисенә посылкалар жибәрә. Аларны алганнан сон, авылда Сабантуй vткәрәләр, кунаклар чакыралар.
Бервакыт Альбина елга янында йоргәндә бер торгәк таба. Шул табышны эзләп Маннур исемле егет килә. Ул хат ташучы Разия белән очраша һәм аны ошата. Әбиләр яна матур

парны берләштерергә булышалар. Алар ойләнешәләр, балалары туа. Бу авылда яна гаилә барлыкка килә - авыл яши.

Наилә НАСЫРОВА